# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об обеспечении жилыми помещениями детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, и о внесении изменения в статью 8 Закона Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
14 февраля 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 12 января 2013 года № 8-ЗРТ «Об обеспечении жилыми помещениями детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, и о внесении изменения в статью 8 Закона Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 1 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 1:

а) дополнить частью $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Жилые помещения, предназначенные для проживания детей-сирот, по договорам найма специализированных жилых помещений не предоставляются иностранным гражданам, лицам без гражданства, если международным договором Российской Федерации не предусмотрено иное.»;

б) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Лица, указанные в части 1 настоящей статьи, однократно подлежат обеспечению жилыми помещениями специализированного жилищного фонда уполномоченным Кабинетом Министров Республики Татарстан органом исполнительной власти Республики Татарстан (далее – уполномоченный орган) по месту их жительства на территории Республики Татарстан.»;

в) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«2[1]. По договорам найма специализированных жилых помещений они предоставляются лицам, указанным в части 1 настоящей статьи, в виде жилых домов, квартир, благоустроенных применительно к условиям соответствующего населенного пункта, по нормам предоставления площади жилого помещения по договору социального найма. Общее количество жилых помещений в виде квартир, предоставляемых лицам, указанным в части 1 настоящей статьи, в одном многоквартирном доме, не может превышать 25 процентов от общего количества квартир в этом многоквартирном доме, за исключением населенных пунктов с численностью жителей менее 10 тысяч человек, а также многоквартирных домов, количество квартир в которых составляет менее десяти.»;

г) часть 4 признать утратившей силу;

2) статью 2 изложить в следующей редакции:

«Статья 2. **Формирование списка детей-сирот, которые подлежат обеспечению жилыми помещениями специализированного жилищного фонда**

1. Уполномоченный орган в порядке, установленном Правительством Российской Федерации, формирует список детей-сирот и лиц, указанных в пункте 9 статьи 8 Федерального закона, которые подлежат обеспечению жилыми помещениями (далее – список) в соответствии с частями 1 и 2 статьи 1 и частями 1 и 1[1] статьи 3 настоящего Закона. Лица, указанные в части 1 статьи 1 настоящего Закона, включаются в этот список по достижении возраста 14 лет.

2. Заявление о включении в список подается законными представителями детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, достигших возраста 14 лет, в течение трех месяцев со дня достижения ими указанного возраста или с момента возникновения оснований предоставления жилых помещений специализированного жилищного фонда.

3. Дети-сироты и дети, оставшиеся без попечения родителей, приобретшие полную дееспособность до достижения ими совершеннолетия, а также лица из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, если они в установленном порядке не были включены в список до приобретения ими полной дееспособности до достижения совершеннолетия либо до достижения возраста 18 лет соответственно и не реализовали принадлежащее им право на обеспечение жилыми помещениями, вправе самостоятельно обратиться с заявлением в письменной форме о включении их в список.

4. Дети-сироты исключаются из списка в случаях, установленных частью 3[1] статьи 8 Федерального закона.»;

3) статью 2[1] изложить в следующей редакции:

«Статья 2[1]. **Порядок установления факта невозможности проживания детей-сирот в ранее занимаемых жилых помещениях**

1. Проживание детей-сирот в ранее занимаемых жилых помещениях, нанимателями и членами семей нанимателей по договорам социального найма либо

собственниками которых они являются, признается невозможным, если это противоречит интересам указанных лиц в связи с наличием одного из обстоятельств, установленных частью 4 статьи 8 Федерального закона, а также в случаях проживания в таких жилых помещениях лиц:

1) не являющихся членами семьи этих детей-сирот, имеющих самостоятельное право пользования жилым помещением;

2) бывших усыновителей этих детей-сирот, если усыновление отменено;

3) признанных в установленном законодательством порядке недееспособными или ограниченных в дееспособности;

4) имеющих или имевших судимость либо подвергающихся или подвергавшихся уголовному преследованию (за исключением лиц, уголовное преследование в отношении которых прекращено по реабилитирующим основаниям) за преступления против жизни и здоровья, половой неприкосновенности и половой свободы личности, против семьи и несовершеннолетних, здоровья населения и общественной нравственности, а также против общественной безопасности;

5) больных хроническим алкоголизмом, наркоманией и психическими заболеваниями и состоящих на учете в соответствующих медицинских организациях.

2. Решение об установлении факта невозможности проживания детей-сирот в ранее занимаемых жилых помещениях принимается межведомственной комиссией, созданной уполномоченным органом (далее – комиссия), на основании письменного заявления лица, указанного в пункте 2 части 1 статьи 1 настоящего Закона, либо его законного представителя и документов, прилагаемых к нему.

3. Требования к заявлению и перечень документов, прилагаемых к нему, состав комиссии, порядок рассмотрения комиссией заявления и документов, порядок принятия решения по результатам такого рассмотрения устанавливаются уполномоченным органом. При этом общий срок рассмотрения комиссией заявления и документов, представленных лицом, указанным в пункте 2 части 1 статьи 1 настоящего Закона, либо его законным представителем не может превышать 14 дней со дня их представления.

4. Решение комиссии оформляется в виде заключения и может быть обжаловано в порядке, установленном законодательством.»;

4) в статье 3:

а) в наименовании слова «жилых помещений детям-сиротам» заменить словами «детям-сиротам жилых помещений специализированного жилищного фонда»;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Жилые помещения специализированного жилищного фонда предоставляются лицам, указанным в части 1 статьи 1 настоящего Закона, по их заявлению в письменной форме по достижении ими возраста 18 лет, а также в случае приобретения ими полной дееспособности до достижения совершеннолетия.»;

в) дополнить частью $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Лицам, указанным в части 1 статьи 1 настоящего Закона и достигшим возраста 18 лет, жилые помещения предоставляются по окончании срока пребывания в образовательных организациях, организациях социального обслуживания, медицинских организациях и иных организациях, создаваемых в установленном законодательством порядке для детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, а также по завершении получения профессионального образования, профессионального обучения, либо окончании прохождения военной службы по призыву, либо окончании отбывания наказания в исправительных учреждениях.»;

г) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Жилые помещения специализированного жилищного фонда предоставляются лицам, указанным в части 1 статьи 1 настоящего Закона, ранее чем по достижении ими возраста 18 лет по окончании срока пребывания в образовательных организациях, организациях социального обслуживания, медицинских организациях и иных организациях, создаваемых в установленном законодательством порядке для детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей.»;

д) часть 3 признать утратившей силу;

е) часть 4 изложить в следующей редакции:

«4. Заявление о предоставлении жилого помещения специализированного жилищного фонда подается лицами, указанными в частях 1 и 2 настоящей статьи, в уполномоченный орган.»;

ж) дополнить частями $5^1$ и $5^2$ следующего содержания:

«$5^1$. В жилые помещения, предоставленные детям-сиротам по договорам найма специализированных жилых помещений, могут быть вселены их несовершеннолетние дети и супруг (супруга). Указанные лица включаются в договор найма специализированного жилого помещения.

$5^2$. В случае смерти лиц, указанных в части 1 статьи 1 настоящего Закона, орган исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющий управление государственным жилищным фондом, обязан принять решение об исключении жилого помещения из специализированного жилищного фонда и заключить с лицами, указанными в части $5^1$ настоящей статьи, договор социального найма в отношении данного жилого помещения в порядке, установленном статьей 5 настоящего Закона.»;

з) часть 6 признать утратившей силу;

5) статью 4 изложить в следующей редакции:

«Статья 4. **Обеспечение сохранности жилых помещений детей-сирот**

Уполномоченный орган во взаимодействии с иными заинтересованными органами исполнительной власти Республики Татарстан в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан, осуществляет контроль за использованием и сохранностью жилых помещений, нанимателями или членами

семей нанимателей по договорам социального найма либо собственниками которых являются дети-сироты и дети, оставшиеся без попечения родителей, за обеспечением надлежащего санитарного и технического состояния жилых помещений, а также осуществляет контроль за распоряжением ими.»;

6) в статье 5:

а) в наименовании слова «на новый срок или» заменить словами «на новый срок, порядок»;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. За три месяца до окончания срока действия договора найма специализированного жилого помещения уполномоченный орган проводит проверку условий жизни нанимателя по указанному договору в целях определения наличия обстоятельств, свидетельствующих о необходимости оказания детям-сиротам содействия в преодолении трудной жизненной ситуации. Порядок выявления этих обстоятельств устанавливается Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

в) в части 4 слова «об однократном заключении» заменить словом «о заключении»;

г) дополнить частью $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. Не позднее 30 дней со дня принятия решения, указанного в части 4 настоящей статьи, уполномоченный орган заключает с ребенком-сиротой договор найма специализированного жилого помещения на новый срок.»;

д) в части 5 слова «расторжении договора найма специализированного жилого помещения и» исключить, слово «данного» заменить словом «этого»;

е) дополнить частью $5^1$ следующего содержания:

«$5^1$. Не позднее 30 дней со дня принятия решения, указанного в части 5 настоящей статьи, или наступления обстоятельства, указанного в части $5^2$ статьи 3 настоящего Закона, орган исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющий управление государственным жилищным фондом, принимает решение об исключении жилого помещения из специализированного жилищного фонда и заключает с ребенком-сиротой или с лицами, указанными в части $5^1$ статьи 3 настоящего Закона, договор социального найма этого жилого помещения.»;

ж) часть 7 признать утратившей силу.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
01 марта 2019 года
№ 20-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Ятим балалар яшәү өчен билгеләнгән торак урыннары махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил гражданнарына, гражданлыгы булмаган затларга бирелми.»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затлар Татарстан Республикасы территориясендә үз яшәү урыны буенча бер мәртәбә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиеш.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«2[1]. Махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча алар әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга социаль яллау шартнамәсе буенча торак урын мәйданы бирү нормалары буенча тиешле торак пунктның шартларына туры китереп төзекләндерелгән торак йортлар, фатирлар рәвешендә бирелә. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга бирелә торган фатирлар рәвешендәге торак урыннарының бер күпфатирлы йорттагы гомуми саны, халык саны 10 мең кешедән ким булган торак пунктлардан, шулай ук фатир саны уннан ким булган күпфатирлы йортлардан тыш, шушы күпфатирлы йорттагы фатирларның гомуми саныннан 25 процентҭан да артык була алмый.»;

г) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 статья. **Махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар исемлеген төзү**

1. Вәкаләтле орган Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләре һәм 3 статьясындагы 1 һәм 1[1] өлешләре нигезендә торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар һәм Федераль законның 8 статьясындагы 9 пунктында күрсәтелгән затлар исемлеген (алга таба – исемлек) төзи. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән затлар бу исемлеккә 14 яшькә җиткәч кертеләләр.

2. Исемлеккә кертү турында гариза 14 яшькә җиткән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләре тарафыннан алар күрсәтелгән яшькә җиткән көннән алып яисә махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү нигезләре барлыкка килү вакытыннан башлап өч ай эчендә бирелә.

3. Балигъ булганчы тулысынча хокукка сәләт алган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, шулай ук ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, әгәр алар билгеләнгән тәртиптә тиешенчә балигъ булганчы тулысынча хокукка сәләт алганга кадәр йә 18 яшькә җиткәнгә кадәр исемлеккә кертелмәгән һәм торак урыннары белән тәэмин ителүгә үз хокукын гамәлгә ашырмаган булсалар, мөстәкыйль рәвештә үзләрен исемлеккә кертү турындагы язма гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Ятим балалар Федераль законның 8 статьясындагы 3[1] өлешендә күрсәтелгән очракларда исемлектән төшереп калдырылалар.»;

3) 2[1] статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2[1] статья. **Ятим балаларның моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булмавы фактын билгеләү тәртибе**

1. Социаль яллау шартнамәләре буенча яллаучылары һәм яллаучыларның гаилә әгъзалары йә милекчеләре булган ятим балалар моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында ятим балаларның яшәве, әгәр бу Федераль законның

8 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән хәлләрнең берсенә генә булса да бәйле рәвештә күрсәтелгән затларның мәнфәгатьләренә каршы килсә, шулай ук мондый торак урыннарында түбәндәге затлар яшәгән очракта, мөмкин түгел дип таныла:

1) торак урыныннан мөстәкыйль файдалану хокукына ия булган шушы ятим балаларның гаилә әгъзалары булмаган затлар;

2) уллыкка алу юкка чыгарылган булса, шушы ятим балаларның элеккеге уллыкка алучылары булган затлар;

3) законнарда билгеләнгән тәртиптә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

4) хөкем ителүе булган яисә элек хөкем ителгән йә кеше гомеренә һәм сәламәтлегенә, җенси кагылгысызлыкка һәм шәхеснең җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халык сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, шулай ук җәмәгать иминлегенә каршы җинаятьләр кылган өчен җинаять эзәрлекләвенә дучар булган яисә элек дучар ителгән затлар (үзләренә карата реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);

5) хроник алкоголизм, наркомания һәм психик авырулар белән авыручы һәм тиешле медицина оешмаларында исәптә торучы затлар.

2. Ятим балаларның моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булмавы фактын билгеләү турында карар вәкаләтле орган төзегән ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) тарафыннан әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән затның йә аның законлы вәкиленең язма гаризасы һәм аңа кушып бирелә торган документлар нигезендә кабул ителә.

3. Гаризага таләпләрне һәм аңа кушып бирелә торган документлар исемлеген, комиссия составын, комиссия тарафыннан гаризаны һәм документларны карау тәртибен, мондый карау нәтиҗәләре буенча карар кабул итү тәртибен вәкаләтле орган билгели. Комиссия тарафыннан әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән зат йә аның законлы вәкиле тапшырган гаризаны һәм документларны карауның гомуми срогы аларны тапшырган көннән алып 14 көннән дә артык була алмый.

4. Комиссия карары бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә, һәм аңа законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.»;

4) 3 статьяда:

а) исемендә «Ятим балаларга торак урыннары» сүзләрен «Ятим балаларга махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән затларга аларның язма гаризасы буенча, 18 яшькә җиткәч, шулай ук балигъ булганчы тулысынча хокукка сәләт алган очракта, бирелә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«1$^1$. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән һәм 18 яшькә җиткән затларга торак урыннар законнарда билгеләнгән тәртиптә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен булдырыла торган белем бирү оешмаларында, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, медицина оешмаларында һәм башка оешмаларда булу срогы тәмамланганнан соң, шулай ук һөнәри белем алу, һөнәри уку тәмамланганнан соң, йә чакырылыш буенча хәрби хезмәт узу тәмамланганнан соң, йә төзәтү учреждениеләрендә җәзаны үтәгәннән соң бирелә.»;

г) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән затларга, алар 18 яшькә җиткәнче, законнарда билгеләнгән тәртиптә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен булдырыла торган белем бирү оешмаларында, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, медицина оешмаларында һәм башка оешмаларда булу срогы тәмамланганнан соң бирелә.»;

д) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

е) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны бирү турында гариза әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән затлар тарафыннан вәкаләтле органга бирелә.»;

ж) түбәндәге эчтәлекле 5$^1$ һәм 5$^2$ өлешләр өстәргә:

«5$^1$. Махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча ятим балаларга бирелгән торак урыннарына аларның балигъ булмаган балалары һәм ире (хатыны) кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән затлар махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенә кертелә.

5$^2$. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән затларның вафаты очрагында, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт торак фонды белән идарә итүче органы торак урынын махсуслаштырылган торак фондыннан төшереп калдыру турында карар кабул итәргә һәм әлеге статьяның 5$^1$ өлешендә күрсәтелгән затлар белән әлеге Законның 5 статьясында билгеләнгән тәртиптә шушы торак урынына карата социаль яллау шартнамәсе төзергә тиеш.»;

з) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

5) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Ятим балалар өчен торак урыннарының сакланышын тәэмин итү**

Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән кызыксынучы органнары белән хезмәттәшлектә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә социаль яллау шартнамәләре буенча яллаучылары һәм яллаучыларның гаилә әгъзалары йә милекчеләре булган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар тарафыннан торак урыннарыннан файдалануны һәм аларның сакланышын, торак урыннарының тиешле санитария хәлен һәм техник торышын тәэмин итүне, шулай ук алар белән эш итүне тикшереп тора.»;

б) 5 статьяда:

а) исемендә «яңа срокка төзү яисә» сүзләрен «яңа срокка төзү тәртибе,» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы өч ай кала вәкаләтле орган ятим балаларга авыр тормыш хәлен җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү зарурлыгын раслый торган хәлләрнең булуын билгеләү максатларында күрсәтелгән шартнамә буенча яллаучының яшәү шартларын тикшерә. Әлеге хәлләрне ачыклау тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.»;

в) 4 өлештә «бер мәртәбә» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча вәкаләтле орган ятим бала белән яңа срокка махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсе төзи.»;

д) 5 өлештә «махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен өзү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «шушы» сүзе татарча текстта үзгәрешсез кала;

е) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

«$5^1$. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән карар кабул ителгән яисә әлеге Законның 3 статьясындагы $5^2$ өлешендә күрсәтелгән хәл барлыкка килгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт торак фонды белән идарә итүче органы махсуслаштырылган торак фондыннан торак урынын төшереп калдыру турында карар кабул итә һәм ятим бала яисә әлеге Законның 3 статьясындагы $5^1$ өлешендә күрсәтелгән затлар белән шушы торак урынын социаль яллау шартнамәсе төзи.»;

ж) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 20-ТРЗ